# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 48** **04.11.2023 ел**

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге
составына керүче Бәйрәкә авылында
гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россиядә Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә авылында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучы ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә; аны 2 төркем инвалидлар өчен бер тапкырга киметеп 300 сум күләмендә билгеләргә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юлларга:

1. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- грейдерлаштыру, кышкы чорда юлларны кардан чистарту (ягулык сатып алу, тракторчы белән техника арендалау, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылындагы Вахитов урамындагы юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета нигезендә юл салу: вак ком-таш катнашмасы, асфальт сатып алу, нигез әзерләү, алып кайту, салу, эшләр өчен түләү);

2. Торак пункт территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Бәйрәкә авылында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктыртуына хезмәт күрсәтү);
- халыкның күпләп ял итү урыннарын (парк) төзү һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү;
- Бәйрәкә авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:

- Бәйрәкә авылында зират территориясендә карт агачларны кисү һәм аларны химик эшкәртү (химик препаратлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О. Әхмәтшина